БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26 июль 2018 ел № 137

**«2018 елга, 2019-2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты турында» 2017 елның 20 декабрендәге 104 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексына, Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында бюджет процессы турында нигезләмәгә таянып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар бирде:**

1. «2018 елга, 2019-2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2017 елның 20 декабрендәге 104 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. 2018 елга Балтач муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Балтач муниципаль районы бюджетының фаразланган гомуми керем күләмен 841347,69 мең сум итеп;

2) Балтач муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 861377,74 мең сум итеп;

3) Балтач муниципаль районы бюджеты кытлыгын 20030,05 мең сум итеп.».

1.2. 1 нче, 3 нче, 6 нчы, 8 нче, 10 нчы, 24 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин